КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 май г.Казань № 381

Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы территориясендә «Сокольский утравы» табигать объектын төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле дип игълан итү турында

«Махсус саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, табигать комплексларын саклап калу, хайваннарның һәм үсемлекләрнең (шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгәннәрнең) су һәм су янындагы төрләрен саклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы территориясендәге 763,4 гектар гомуми мәйданлы «Сокольский утравы» табигать объектын – төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле, шулай ук ул биләгән территорияне төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре дип игълан итү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Сокольский утравы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турындагы нигезләмәне;

«Сокольский утравы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре урнашу урынының график тасвирламасын.

3. Территориаль планлаштыру документларын эшләгәндә, җирләргә инвентаризация үткәргәндә «Сокольский утравы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләрен һәм аның махсус саклау режимы үзенчәлекләрен исәпкә алырга.

4. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасының махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

финанслар бүлеп бирелгәннән соң бер ел эчендә «Сокольский утравы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре турындагы мәгълүматларны «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалына билгеләнгән тәртиптә кертүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 27 май, 381 нче
карары белән расланды

## «Сокольский утравы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Сокольский утравы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле (алга таба – табигать һәйкәле) табигать комплексларын саклап калу, үсемлекләрнең һәм хайваннарның суда һәм су янында үсә һәм яши торган төрләрен саклау максаты белән оештырылган төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясе булып тора.

Табигать һәйкәле Мамадыш муниципаль районы территориясендә урнашкан һәм аның гомуми мәйданы 763,4 гектар тәшкил итә.

1.2. Табигать һәйкәле Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

Табигать һәйкәленең чикләре җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнә.

1.3. Табигать һәйкәле Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет) карамагында тора.

Комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 нчы йорт.

1.4. Табигать һәйкәленең чикләре һәм махсус саклау режимы үзенчәлекләре территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман корылышы эшчәнлеген башкарганда һәм җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

### II. Табигать һәйкәле эшчәнлеген оештырганда Комитетның төп бурычлары

2.1. Табигать һәйкәле эшчәнлеген оештырганда Комитетның төп бурычлары түбәндәгеләр була:

биологик төрлелекне саклап калуны тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре системасын үстерү һәм камилләштерү.

## III. Табигать һәйкәле эшчәнлеген оештырганда Комитетның функцияләре

3.1. Комитет табигать һәйкәле эшчәнлеген оештыру буенча үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм яңадан торгызу белән идарә итү, хайваннар дөньясы объектларын файдалануны җайга салу;

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшләве өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару;

төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге (табигать дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитария (тау санитариясе) саклавын тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген кертеп).

## IV. Табигать һәйкәленең махсус саклау режимы

4.1. Табигать һәйкәле территориясенең махсус саклау режимы (алга таба – махсус саклау режимы) табигать һәйкәлен булдыру максатларыннан һәм әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге законнардан чыгып билгеләнә.

4.2. Табигать һәйкәле территориясендә табигать һәйкәленең сакланышын бозуга китерә торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

торак пунктлар, коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре төзү;

капиталь төзелеш объектларын, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен җир кишәрлекләре (бу Нигезләмәнең 4.3 пунктында каралган очраклардан тыш) бирү;

әгәр дә түбәндәгеләрне төзү табигать һәйкәленең эшчәнлеге белән бәйле булмаса һәм җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнешенә туры килмәсә, капиталь төзелеш объектлары, индивидуаль торак төзелеше объектлары, шул исәптән линия объектлары (бу Нигезләмәнең 4.3 пунктында каралган очраклардан тыш) төзү;

механик транспорт чаралары йөрү һәм туктап тору (печән әзерләү өчен файдаланыла торган транспорттан, махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органнарның, табигать һәйкәле чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башка дәүләт органнарының тарнспортыннан, линия объектларына хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру өчен махсус техникадан, шулай ук һәлакәтләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характерда булган башка вакыйгаларны бетерү чараларын үткәрүне тәэмин итә торган транспорттан, сәнәгать максатында балык үрчетүне һәм аучылык хуҗалыгы килешүләре нигезендә хайваннар дөньясыннан файдалануны гамәлгә ашыручы юридик затларның (индивидуаль эшмәкәрләрнең) транспортыннан тыш), шулай ук уылдык чәчү чорында азсыешлы суднолар йөрү һәм туктап тору;

автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

агып җыела торган суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

гидромелиорация һәм ирригация эшләрен үткәрү;

учак ягу өчен махсус каралган урыннардан читтә учаклар ягу;

хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларының авыруларын һәм үлүләрен булдырмауны гарантияли торган чараларны гамәлгә ашырудан, шулай ук аларның яшәү мохитен начарландырудан башка үсемлекләрне яндыру, агулы химикатларны, ашламаларны, хайваннар дөньясы объектлары һәм аларның яшәү тирәлеге өчен башка куркыныч булган материалларны, чималларны һәм җитештерү калдыкларын саклау һәм куллану;

җитештерү һәм куллану калдыкларын, химик, шартлаткыч, токсинлы, агулый торган һәм агулы матдәләрне урнаштыру объектларын, радиоактив калдыкларны күмү пунктларын булдыру;

җирле флорага һәм фаунага чит булган үсемлекләрне һәм хайваннарны интродукцияләү;

Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләргә караган үсемлекләр, хайваннар һәм башка организмнарның санын киметүгә китерә һәм аларның яшәү мохитен начарайта торган эшчәнлек;

аучылык объектларына кертелмәгән хайваннарны аулау (санны җайга салу максатларында аулаудан тыш), шулай ук Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар, үсемлекләр һәм гөмбәләр төрләрен аулау һәм җыю;

кырмыска ояларын, хайваннарның ояларын, өннәрен һәм башка яшәү урыннарын юк итү (җимерү), шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр;

куышлы агачларны юк итү;

1 апрельдән 31 июльгә кадәр оя корып бала чыгару чорында агачлар кисү (һәлакәтләр, табигый бәла-казалар һәм гадәттән тыш характерга ия башка вакыйгалар булган очраклардан тыш);

азык-төлек урман ресурсларын хәзерләү һәм дару үсемлекләрен, шулай ук агач булмаган башка урман ресурсларын җыю (законнарда билгеләнгән тәртиптә үз ихтыяҗлары өчен аларны хәзерләүдән һәм җыюдан тыш);

туфрак катламын бозу, җир эшләрен башкару (урманнарны янгынга каршы тәртипкә китерү чараларын гамәлгә ашырудан, фәнни тикшеренүләр үткәрүдән тыш, әлеге эшчәнлек табигать комплексларын һәм объектларын саклау һәм торгызу максатларында башкарыла торган һәм (яки) бу пункт таләпләренә каршы килми торган төзелеш белән бәйле очраклардан тыш);

файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнүне һәм аларның яраклылыгын бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнүне үткәрү (әлеге эшчәнлекне табигать һәйкәлен булдырылганга кадәр бирелгән лицензияләр буенча җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары нигезендә гамәлгә ашырудан тыш);

табигать һәйкәле территориясендә аншлагларны, мәгълүмат бирү характерындагы махсус билгеләрне, җиһазландырылган экологик сукмакларны, төзелмәләрне һәм корылмаларны бетерү һәм аларга зыян китерү, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

табигать комплексының экологик тигезлеген боза торган, бу территориянең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының саклана торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

4.3. Табигать һәйкәле территориясендә, Комитет белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

махсус саклау режимы рөхсәт итә торган төзелеш объектлары өчен җир кишәрлекләре бирү;

социаль әһәмиятле объектлар, гидротехник корылмалар, биотехник корылмалар төзү;

элек төзелгән капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линия объектларын, инженерлык-техник коммуникацияләрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау, линия объектларын карап тоту;

төбәк геологиясен өйрәнү;

экологик тернәкләндерү һәм рекультивацияләү үткәрү;

Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләргә карый торган үсемлекләрне, хайваннарны һәм башка организмнарны, шулай ук аларның яшәү тирәлеге мохитен саклау чараларын гамәлгә ашыру;

Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләргә карый торган үсемлекләрнең, хайваннарның һәм башка организмнарның яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

урман утыртмаларын сайлап алып яки тоташтан кисү;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

фәнни-тикшеренү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

торак (палатка шәһәрчекләре, кемпинглар, торак вагоннары, торак прицеплары) сыйфатында куллануга яраклы корылмалар урнаштыру.

4.5.Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә табигать һәйкәле чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төп төрләре, әгәр дә алар бу Нигезләмәнең IV бүлегендәге таләпләренә каршы килмәсә, рөхсәт ителә:

печән чабу (1.19*);

күчмә торак (Комитет белән килештереп) (2.4*);

фәнни тикшеренүләр үткәрү (Комитет белән килештереп) (3.9.2*);

---

*Код билгеләнеше Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча.

табигатьне танып белү туризмы (Комитет белән килештереп) (5.2*);

җир асты байлыкларыннан файдалану (бары табигать һәйкәле булдырылганга кадәр җир асты байлыкларыннан файдалану өчен бирелгән лицензияләр буенча гына) (6.1*);

табигать территорияләрен саклау (9.1*);

тарихый-мәдәни эшчәнлек (Комитет белән килештереп) (9.3*);

урманнардан файдалану (Комитет белән килештереп) (10*);

урман ресурсларын хәзерләү (бары гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен генә) (10.3*);

резерв урманнары (10.4*);

су объектлары (11.0*);

су объектларыннан гомуми файдалану (Комитет белән килештереп) (11.1*);

су объектларыннан махсус файдалану (Комитет белән килештереп) (11.2*);

гидротехник корылмалар (Комитет белән килештереп) (11.3*).

4.5. Табигать һәйкәле территориясендә хуҗалык эшчәнлеге билгеләнгән махсус саклау режимы, Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу буенча таләпләрне раслау турында» 1996 елның 13 августындагы 997 номерлы карарын үтәү йөзеннән әзерләнгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу буенча таләпләр турында» 2000 ел, 15 сентябрь, 669 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу буенча таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## V. Табигать һәйкәле территориясендә рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары

5.1. Табигать һәйкәле территориясендә рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары:

биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның иң чик катлары – ике кат;

җир кишәрлеге чикләрендә төзелеш проценты – иң күбе 50 процент.

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 27 май, 381 нче
карары белән расланды

«Сокольский утравы» төбәк әһәмиятендәге
табигать һәйкәле чикләре урнашу урынының
график тасвирламасы

1 бүлек

| «Сокольский утравы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турында мәгълүматлар (алга таба – объект) | | |
|---|---|---|
| Т/с | Объектның тасвирнамәләре | Тасвирнамәләрнең тасвирламасы |
| 1. | Объектның урнашу урыны | Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы |
| 2. | Объектның мәйданы +/- мәйданны билгеләү төгәлсезлеге зурлыгы (Р +/- Дельта Р) | 7 633 881,60 кв.метр |
| 3. | Объектның башка тасвирнамәләре | - |

2 бүлек

| Объект чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы: МСК-16 | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Координатлар, метр | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр | Җирлектә ноктаны билгеләү тасвир-ламасы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | 446561.452 | 1455529.769 | Картометрик | 5 | - |
| 2 | 446715.392 | 1455628.679 | Картометрик | 5 | - |
| 3 | 447172.627 | 1455952.724 | Картометрик | 5 | - |
| 4 | 447668.11 | 1456411.294 | Картометрик | 5 | - |
| 5 | 448026.01 | 1456666.646 | Картометрик | 5 | - |
| 6 | 448343.927 | 1456925.281 | Картометрик | 5 | - |
| 7 | 448559.578 | 1456972.578 | Картометрик | 5 | - |
| 8 | 448869.53 | 1457163.798 | Картометрик | 5 | - |
| 9 | 449204.38 | 1457396.451 | Картометрик | 5 | - |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 10 | 449393.501 | 1457511.67 | Картометрик | 5 | - |
| 11 | 449627.871 | 1457614.507 | Картометрик | 5 | - |
| 12 | 449793.444 | 1457725.493 | Картометрик | 5 | - |
| 13 | 450058.21 | 1457836.696 | Картометрик | 5 | - |
| 14 | 450424.031 | 1457999.86 | Картометрик | 5 | - |
| 15 | 450309.78 | 1458323.767 | Картометрик | 5 | - |
| 16 | 450015.728 | 1458636.495 | Картометрик | 5 | - |
| 17 | 449184.543 | 1458918.145 | Картометрик | 5 | - |
| 18 | 448886.38 | 1458993.425 | Картометрик | 5 | - |
| 19 | 448539.218 | 1459038.876 | Картометрик | 5 | - |
| 20 | 448305.454 | 1459046.079 | Картометрик | 5 | - |
| 21 | 447972.249 | 1459046.134 | Картометрик | 5 | - |
| 22 | 447577.3 | 1458910.558 | Картометрик | 5 | - |
| 23 | 447222.743 | 1458659.022 | Картометрик | 5 | - |
| 24 | 446782.467 | 1458223.945 | Картометрик | 5 | - |
| 25 | 446628.442 | 1458062.505 | Картометрик | 5 | - |
| 26 | 446487.915 | 1457873.369 | Картометрик | 5 | - |
| 27 | 446346.086 | 1457585.588 | Картометрик | 5 | - |
| 28 | 446310.945 | 1457413.525 | Картометрик | 5 | - |
| 29 | 446302.562 | 1457023.533 | Картометрик | 5 | - |
| 30 | 446376.667 | 1456476.894 | Картометрик | 5 | - |
| 31 | 446343.615 | 1456424.937 | Картометрик | 5 | - |
| 32 | 446377.747 | 1456256.731 | Картометрик | 5 | - |
| 33 | 446445.514 | 1456219.532 | Картометрик | 5 | - |
| 34 | 446477.164 | 1455981.21 | Картометрик | 5 | - |
| 35 | 446447.076 | 1455729.9 | Картометрик | 5 | - |
| 36 | 446473.002 | 1455580.972 | Картометрик | 5 | - |
| 1 | 446561.452 | 1455529.769 | Картометрик | 5 | - |
| 3. Объект чигенең бер өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Координатлар, метр | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр | Җирлектә ноктаны билгеләү тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| - | - | - | - | - | - |

# 3 бүлек

| Объектның үзгәртелгән (тәгаенләнгән) чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы | | | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Гамәлдәге координатлар, метр | | Үзгәртелгән (тәгаенләнгән) координатлар, метр | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр | Җирлектә ноктаны билгеләү тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | X | Y | | | |
| - | - | - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чигенең бер өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | | | |
| - | - | - | - | - | - | - | - |